

Быел Жинv конендә Ельники районы Большие Уркатлылар яна асфальт аша vтеп, һәлак булган сугышчылар һәйкәленә чәчәкләр салдылар. Бу бvләкне аларга «ЕДСПМК» оешмасы эшчеләре тапшырды. Бvгенге кондә алар эшнен топ кvләмен тәмамлаган инде. Якын киләчәктә юлчылар юл кырыйларын, бордюрларны тозекләндерә башлаячак. Юлнын озынлыгы километр ярымнан артык. Тозелеш-монтаж эшләренен бәясе 13 миллион 400 мен сум тәшкил итәчәк.      Ельники авылында Тимирязев урамында яшәvчеләр очен нәкъ шундый ук бvләкне май коннәрендә югарыда аталган оешманын юлчылары тапшырды. Кырык ел эчендә бу урамда асфальт берботен чокырларга әверелгән. Бvген яна полотно кvзне шатландыра. Анын озынлыгы 153 метр. «ЕДСПМК» оешмасы юл тозvчеләренә быел зур кvләмдә эшләр башкарырга туры киләчәк. Оешма Мордовское Корино авылына кадәр автоюлнын икенче участогын капиталь ремонтлау тендерында жинде. Трассанын озынлыгы жиде километрдан артык. Кыш айларында оешманын шоферлары тулы кvләмдә ныклы вак таш алып киләләр, ботен эш чорында битум һәм башка тозелеш материаллары белән тәэмин итәләр. Мондый задел юлчыларнын озлексез эшләвен тәэмин итәргә момкинлек бирәчәк. Моннан тыш, эшчеләргә Кабаново авылында урамнар буйлап асфальт жәю бурычы куела. Ара бер километрдан артык.

Ельники районында юл тозелеше объектларыннан тыш, коллективка Теньгушево районында асфальт салу буенча зур кvләмдә эш башкарырга туры киләчәк.

Быел Мещеров урамы буенча юл тозv планлаштырыла. Район башлыгынын беренче урынбасары А.В.Малоземов сvзләренчә, хәзер конкурс процедураларын vткәрvгә аукцион документациясе әзерләнә.